КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 2 сентябрь г.Казань № 713

2024 елда мәгариф оешмаларының бердәм дәүләт имтиханында максималь күләмдә балл җыйган тәмамлаучыларына бер тапкыр бирелә торган түләү билгеләү турында

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан мәгариф оешмаларының бердәм дәүләт имтиханында максималь санда балл җыйган тәмамлаучыларын бүләкләү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан мәгариф оешмаларының бердәм дәүләт имтиханында максималь санда балл җыйган тәмамлаучыларына, 2024 елда максималь җыелган нәтиҗәдән чыгып, бер тапкыр бирелә торган түләү билгеләргә:

өч уку предметы буенча – 35 000,0 сум күләмендә (физик затлар керемнәренә салымны исәпкә алып);

ике уку предметы буенча – 25 000,0 сум күләмендә (физик затлар керемнәренә салымны исәпкә алып);

бер уку предметы буенча – 15 000,0 сум күләмендә (физик затлар керемнәренә салымны исәпкә алып).

2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан мәгариф оешмаларының бердәм дәүләт имтиханында максималь санда балл җыйган тәмамлаучыларына бер тапкыр бирелә торган түләү тәртибен эшләргә һәм расларга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин